РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ

БОЕРЫК

«18» октября 2022г. с. Тюлячи № 835

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 7 сентябрендәге 174 номерлы «Муниципаль бюджет учреждениесе - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Җирлекара китапханәсе тарафыннан түләүле хезмәтләр һәм керем китерә торган башка эшчәнлек күрсәтү турында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Указы нигезендә, Теләче муниципаль районының муниципаль мөлкәтен нәтиҗәле файдалану максатларында,

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 7 сентябрендәге 174 номерлы «Муниципаль бюджет учреждениесе - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Җирлекара китапханәсе тарафыннан түләүле хезмәтләр һәм керем китерә торган башка эшчәнлек күрсәтү турында» боерыгы белән расланган муниципаль бюджет учреждениесе - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Җирлекара китапханәсендә 2022-2023 елга түләүле хезмәт күрсәтүләргә бәяләр прейскурантына, түбәндәге эчтәлектә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
07.09.2022 № 174 боерыгына 2
номерлы кушымта

Муниципаль бюджет учреждениесе - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Җирлекара китапханәсендә 2022-2023 елга түләүле хезмәт күрсәтүләргә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәя |
|---|---|---|---|
| 1 | Күчермәләү | 1 бит | 3 сум |
| 2 | Фәнни-популяр басмаларның түләүле абонементы (дәреслекләр, методик материаллар) 50 сум залог белән | 1 көн | 50 сум |
| 3 | Төнге абонемент 16.00 дән - киләсе көннең 9.00 кадәр:<br>- энциклопедияләр һәм 60 сум залоглы сүзлекләр;<br>- 50 сум залоглы журналлар;<br>- 50 сум залоглы газеталар | 1 төн | <br>50 сум<br>10 сум<br>10 сум |
| 4 | Сценарийны эчтәлеккә карап сату | | 150-450 сум |
| 5 | 50 сум залоглы аудио һәм видеодискларны вакытлыча алып тору | 1 көн | 10 сум |
| 6 | Компьютерда текст җыю | 1 бит. | 50 сум |
| 7 | Документларны сканерлау | 1 бит. | 10 сум |
| 8 | Уку залы арендасы | 1 сәгать | 400 сум |
| 9 | Техник чаралар кулланып уку залын арендалау (проектор, экран) | 1 сәгать | 700 сум |
| 10 | Проекторны вакытлыча алып тору | 1 сәгать | 100 сум |
| 11 | Экранны вакытлыча алып тору | 1 сәгать | 50 сум |
| 12 | Фотоаппарат өчен җайланманы вакытлыча алып тору | 1 сәгать | 100 сум |
| 13 | Документларга ламинирование ясау (А4 форматы) | 1 экз. | 50 сум |
| 14 | А4 документларын брошюровкалау | 1 җыентык | 300 сум |
| 15 | Мәдәни-агарту, фәнни-техник һәм белем бирү характерындагы чараларны оештыру һәм үткәрү, шул исәптән Пушкин картасы буенча | 1 чара | 100 сум |
| 16 | Китапханә буенча экскурсия | 1 кеше | 50 сум |
| 17 | Китапханә фондларыннан документлар югалган яки бозылган өчен компенсация | 1 документ | Документларның агымдагы янадан эшләү бәясе күләме |
| 18 | Китапханә интерьерларын түбәндәгеләр өчен бирү:<br>- фотога төшерү;<br>- видеога төшерү | <br><br>1 сәгать<br>1 сәгать | <br><br>600<br>600 |

Гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен бушлай бару һәм хезмәтләр күрсәтү:

- Бөек Ватан сугышында катнашучылар, хәрби хәрәкәтләр ветераннары;
- балалар - ятимнәр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча чакырылган гражданнарның гаиләләреннән балалар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләреннән балалар.

Бушлай керү хокукын алу өчен раслаучы документны тәкъдим итәргә кирәк.».

2. Әлеге боерык гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2022 елның 10 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин